Татарстан Республикасы  Әлмәт муниципаль районыны
Түбән Мактама бистә  Советы

КАРАРЫ

11  декабрь  2020 ел № 14

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012елның 27 декабрендәге 119 номерлы Түбән Мактама бистә Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт районы муниципаль берәмлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия тәкъдиме, 2008 елның 1 декабрендәге 93/1 номерлы Түбән Мактама бистә Советы карары белән расланган «Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар үткәрү турында нигезләмә» нигезендә, «Гавами тыңлауларны билгеләү турында» Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге башлыгының 2020 елның 18 сентябрендәге 5 номерлы карары нигезендә

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012елның 27 декабрендәге 119 номерлы Түбән Мактама бистә Советы карары кушымтасына V класслы куркыныч җитештерү-коммуналь объектларының территориаль (П5) зонасын киметү һәм территориаль зона билгеләү өлешендә шәһәр төзелеше зонасы картасына үзгәрешләр кертергә 16:45:070114:585 һәм 16:45:070114:584 кадастр номеры (рөхсәт ителгән хосусый милек: җитештерү базасы, мәйданы) - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш (Д-1), Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә шәһәр җирлеге, Түбән Мактама ш.т.б., Промышленная ур., 3Б й  адресы буенча урнашкан.

2. Әлеге карарны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Тихоновка авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Мактама ш.т.б. Башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы  бистә  Башлыгы Р.А. Бәдретдинов